ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2023 г. Казань № 769-165/кс-2023

«Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2021 №506-164/кс-2021 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2024 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 18.12.2023 №60-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә, 2024 елга эчә торган суга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Пиптрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчә торган суга 2022-2024 елларга тарифлар билгеләү турында» 10.12.2021 №506-164/кс-2021 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 №388-104/кс-2022 карары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Салкын су белән тәэмин итүне хәл итүче «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «Питрәч коммуналь челтәрләре» МУП) өчен, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләргә.»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

4 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

"4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Питрәч коммуналь челтәрләре» МУП иректле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
10.12.2021 № 506-164/кс-2021
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2023 № 769-165/кс-2023 карары
редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Питрәч коммуналь челтәрләре» МУП өчен эчәргә яраклы суга 2022-2024 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 | | 2023 | 2024 | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр |
| | Питрәч муниципаль районы | | | | | |
| 1 | «Питрәч коммуналь челтәрләре» МУП* (Богородское авыл җирлеге кулланучылары) | 27,73 | 29,08 | 30,00** | 23,55 | 23,55 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.
<**> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 №388-104/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге